# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фондына 1994 елның I яртыеллыгындагы кертемнәрнең иминлек тарифы турында**

<u>1 статья.</u> 1994 елның 1 яртыеллыгында Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фондына кертемнәрнең иминлек тарифын хезмәт өчен түләүнең һәрьяклап исәпләнелгән суммасына карата түбәндәге күләмдә билгеләргә:

милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык объектлары өчен - ике процент;

колхозлар һәм совхозлар өчен - бер процент.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фондына иминлек кертемнәрен түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

гарипләрнең җәмәгатьчелек оешмалары һәм дини берләшмәләр, шулай ук алар милкендә булган һәм барлык табышларын аларның устав максатларын башкаруга кулланучы предприятиеләр, берләшмәләр һәм учреждениеләр.

<u>3 статья.</u> Әлеге акчаларны үз вакытында һәм тулысынча күчерелүен тикшереп тору Дәүләт салым хезмәте һәм Татарстан Рес-

публикасының банк учреждениеләре белән берлектә Халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәтенә йөкләтелә.

4 статья. Әлеге Законны 1994 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы

Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,

1994 елның 9 феврале

N 2077-XII